КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 30 ноябрь г.Казань № 1068

Яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2021 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «2013 – 2021 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«2015 елда яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь төзәтү эшләрен башкару белән бәйле финанс ягыннан тәэмин итүгә авыл хуҗалыгы товарларын

җитештерүчеләргә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 7 август, 572 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь төзәтү эшләрен башкару белән бәйле финанс ягыннан тәэмин итүгә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 7 август, 572 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 20 февраль, 105 нче;

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 30 ноябрь, 1068 нче
карары белән расланды

Яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь ремонтлау эшләрен
башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы
товар җитештерүчеләренә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә
Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип яшелчә продукциясен һәм бәрәңгене саклауны һәм (яки) эшкәртүне тәэмин итү максатларында яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына (алга таба – Баш эш итүче) бюджет акчасы белән баш эш итүче буларак билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга акча белән эш итүче булып Баш эш итүченең ведомство буйсынуындагы «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Акча белән эш итүче) тора.

4. Баш эш итүче акчаны Татарстан Республикасының Финанс министрлыгында ачылган шәхси счеттан Акча белән эш итүченең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетына күчерүне гамәлгә ашыра.

5. Субсидия алучыны сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр була:

яшелчә һәм бәрәңге үстерү, саклау һәм эшкәртү эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

алучыны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән раслана торган тиешле финанс елында капиталь ремонт ясалырга тиешле яшелчә-бәрәңге саклагычлар исемлегенә (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы) кертү.

6. Субсидия Акча белән эш итүче тарафыннан алучы белән субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзергә планлаштырыла торган айга кадәр булган айның беренче көненә субсидия алучының түбәндәгеләргә туры килү шарты белән бирелә:

закон белән билгеләнгән тәртиптә теркәлү һәм җитештерү эшчәнлеген

Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру;

субсидия алучы – юридик зат үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процессында булмау, ә субсидия алучы – индивидуаль эшмәкәр эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмау;

чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (офшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән россия юридик заты булып тормау;

бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алучы булмау;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмау;

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау.

7. Яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен алучыга бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_1 = P_1\ 30 \times \%,$$

монда:

$W_1$ – яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия күләме;

$P_1$ – яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле рәвештә фактта тотылган һәм документлар белән расланган, әмма тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән расланган яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь ремонтлауның смета кыйммәтеннән артып китмәгән чыгымнар.

8. Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр алучыларга яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь ремонтлау буенча төзелеш-монтаж эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга бирелә.

9. Субсидияләр алу өчен алучы Акча белән эш итүчегә түбәндәге документларны тапшыра:

Акча белән эш итүченең боерыгы белән расланган форма буенча, үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, шул исәптән түбәндәгеләр турында мәгълүматы булган субсидияләр бирү турында гариза:

субсидия алучының закон белән билгеләнгән тәртиптә теркәлүе һәм

җитештерү эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыруы;

субсидия алучы – юридик зат үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процессында тормавы, ә субсидия алучы – индивидуаль эшмәкәр эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмавы;

субсидия алучының чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (офшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 процenttан артып киткән россия юридик заты булып тормавы;

субсидия алучының бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алучы булмавы;

субсидия алучының субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмавы;

субсидия алучының Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавы;

яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь ремонтлауга локаль смета исәп-хисаплары күчермәләрен теркәп, җыелма смета исәп-хисаплары күчермәләрен;

яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь ремонтлау буенча эшләр башкаруга подряд шартнамәләре күчермәләрен (булганда);

яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь ремонтлау буенча КС-2 номерлы «Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт» дигән статистика формасы буенча белешмә кәгазьләре күчермәләрен;

яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь ремонтлау буенча КС-3 номерлы «Башкарылган эшләр һәм чыгымнар турында белешмә кәгазе» дигән статистика формасы буенча белешмә кәгазьләре күчермәләрен;

яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь ремонтлау буенча яшерен эшләргә актлар белән башкару документлары күчермәләрен, кабул итү комиссиясе акты күчермәләрен;

Баш эш итүче тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмә кәгазен;

субсидияләр алучыларның гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга кертелгән барлык үзгәрешләр турында документлар күчермәләрен;

субсидия алучы җитәкчесе вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләрен.

Тапшырылган документларның күчермәләре субсидия алучылар тарафыннан раслана.

10. Субсидия алучы үз инициативасы белән түбәндәге документларны Акча

белән эш итүчегә тапшырырга хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык күчермәсен яки индивидуаль эшмәкәр буларак физик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык күчермәсен, яки Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан, Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан язу бите күчермәсен;

салым органында исәпкә кую турындагы таныклык күчермәсен;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан, Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

алучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавын раслый торган салым органы белешмә кәгазен.

Субсидия алучы тарафыннан әлеге документлар тапшырылмаган очракта, Акча белән эш итүче әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

11. Акча белән эш итүче:

субсидияләр бирү турындагы гаризаларны алар кергән көндә терки;

гариза теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче 15 көн эчендә:

тапшырылган документларның бу Тәртипнең 5, 6, 9 нчы пунктларында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә Килешү төзи.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр түбәндәгеләр була:

документларны тулы комплектта тапшырмау яки алар бу Тәртип таләпләренә туры килмәү;

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүмат дөрес булмау;

бюджет йөкләмәләре лимиты булмау.

Бюджет йөкләмәләре лимиты җитәрлек булмаган очракта, субсидияләр гаризалар бирү чираты тәртибендә бирелә.

Субсидияләр бирүдән баш тарткан очракта, Акча белән эш итүче алучыга бу пунктның өченче абзацында күрсәтелгән вакыт чыкканнан соң эш көннәрендә исәпләнүче биш көн эчендә баш тарту турында хәбәрнамә җибәрә.

12. Килешүдә түбәндәгеләр күздә тотыла:

а) субсидия күләме һәм аның максатчан билгеләнеше, күчерү тәртибе;

б) субсидияләр бирү нәтиҗәлелеге күрсәткеченең әһәмияте;

в) субсидия алучы тарафыннан Баш эш итүчегә субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешү турындагы хисап документлары һәм башка хисаплар кертү формасы һәм вакытлары;

г) субсидия алучының (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм аларның устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашындагы җәмгыятьләрдән, шулай ук аларның устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында коммерция оешмаларыннан тыш) Баш эш итүче, Акча белән эш итүче һәм дәүләт финанс тикшерүендә тоту органнарына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү максатлары, шартлары, һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга

ризалыгы;

д) Баш эш итүче, Акча белән эш итүче һәм дәүләт финанс тикшерүендә тоту органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр йомгаклары буенча аны бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе бозылу фактлары билгеләнгән очракта, субсидияне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару тәртибе.

13. Субсидия бирү нәтиҗәлелегенең күрсәткече булып субсидияләр биргәннән соң өч ел эчендә яшелчә продукциясен һәм бәрәңгене саклау һәм (яки) эшкәртү тора.

14. Акча белән эш итүче акчаны Килешүгә кул куелган көннән эш көннәрендә исәпләнүче 10 көн эчендә үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган шәхси счетыннан субсидия алучының хисап счетына күчерә.

15. Акча белән баш эш итүче, Акча белән эш итүче һәм вәкаләтле дәүләт финанс тикшерүендә тоту органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча бу Тәртип һәм Килешү белән билгеләнгән аларны бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен бозу фактлары билгеләнгән очракта, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешмәгән очракта, бирелгән субсидияләр Баш эш итүченең, Акча белән эш итүченең тиешле таләбен алган көннән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә бюджет законнары нигезендә кире кайтарылырга тиеш.

16. Бу Тәртипнең 15 нче пунктында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджетына ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, алар Баш эш итүче тарафыннан законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

17. Баш эш итүче, Акча белән эш итүче һәм дәүләт финанс тикшерүендә тоту органнары законнар нигезендә субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

18. Субсидия алучы тарафыннан Акча белән эш итүчегә тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык субсидия алучының җитәкчесенә, тиешле вазыйфаи затларга йөкләнә.

19. Бюджет акчасын максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны Баш эш итүче гамәлгә ашыра.